ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 112 от « 09 » 04 2026 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының
2023 елның 17 маендагы 198 номерлы карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыруның аерым мәсьәләләре турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 2026 елның 21 февралендәге 12-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 17 маендагы 198 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында” нигезләмәгә (алга таба-Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.5 пунктында “Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык” сүзләрен “Маршрутның тиешле төре реестрында язылу” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 5.2 пунктында “Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның тиешле маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык” сүзләрен “Маршрутның тиешле төре реестрында язылу” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://madysh.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының http://pravo.tatarstan.ru рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М.Ефимов

0000015240